СОВЕТ ЦИПЬИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 10, с. Ципья, 422243

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧЕПЬЯ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Ленин ур., 10 нчы йорт, Чепья а., 422243

Тел.: (84368) 3-43-41, факс: (84368) 3-43-41. E-mail: Cip.Blt@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

# КАРАР

28 декабрь 2024 ел №143

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлегенең 20.12.2023 ел, № 109 «Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлегенең 2024 елга бюджеты һәм 2025 һәм 2026 еллар план чоры» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

Авыл җирлеге баш бухгалтерының Балтач муниципаль районының Чепья авыл җирлеге бюджетына 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Чепья авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге Советының «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Чепья авыл җирлеге бюджеты турында»2023 елның 20 декабрендәге 109 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1. 2024 елга Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга.:

1) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Чепья авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 15 502,938 мең сум итеп.

2) Балтач муниципаль районының Чепья авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 16 513,255 мең сум итеп;

3) бюджет чыгымнары күләмен 2024 елның 1 гыйнварына четьино авыл җирлегенең исәп-хисап счетындагы акчаларның ирекле калдыгы исәбеннән, авыл җирлеге бюджетына күчерелә торган гражданнарның үзара салым акчалары исәбеннән, өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен авыл җирлекләре бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар исәбеннән арттырыр.

4) Балтач муниципаль районының Чепья авыл җирлеге бюджеты кытлыгын- 1010,317 мең сум итеп. Бюджет кытлыгын арттыруны 01.01.2024 елга җирлек счетындагы калган акчалар исәбенә башкарырга.

2. 1,3,5,7 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә".

Чепья авыл җирлеге башлыгы А.Г. Нотфуллин